МИНИСТЕРСТВО
ОБРАЗОВАНИЯ И НАУКИ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МӘГАРИФ ҺӘМ ФӘН
МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

26.04.2019 Казан ш. № под-722/19

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының «Ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар исәбендәге затларны торак урыннары белән тәэмин итүнең аерым мәсьәләләре турында» 2015 елның 17 августындагы под-8891/15 номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү хакында

«Ятим балаларга һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга социаль ярдәм буенча өстәмә гарантияләр турында» 1996 елның 21 декабрендәге 159-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Торак урыннары белән тәэмин ителергә тиешле ятим балаларның һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларның, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар исәбендәге затларның, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар категориясенә караган затларның, ятим һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган һәм 23 яшенә җиткән балалар исәбендәге затларның исемлеген формалаштыру, ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар исәбендәге затларны Россия Федерациясе субъектында элеккеге яшәгән урыны буенча исемлектән төшерү һәм аларны Россия Федерациясе субъектында яңа яшәү урыны буенча исемлеккә кертү турында» 2019 елның 4 апрелендәге 397 номерлы карары, «Ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны торак урыннары белән тәэмин итү турында һәм «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм турында» Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына үзгәреш кертү хакында» 2013 елның 12 гыйнварындагы 8-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә боерык бирәм:

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының «Ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар исәбендәге затларны торак урыннары белән тәэмин итүнең аерым мәсьәләләре турында» 2015 елның 17 августындагы под-8891/15 номерлы боерыгына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктта «мөмкин булмау шартлары» сүзләрен «мөмкин булмау факты» сүзләренә алмаштырырга;

2 пунктта өченче абзацны көчен югалткан дип танырга;

боерыкның 3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тотуны министр урынбасары А.М.Әсәдуллинага йөкләргә.»;

боерыкка 1 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымтада бирелә).

Татарстан Республикасы
Премьер министры урынбасары – министр Р.Т.Борһанов

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының 2015 елның 17 августындагы под-8891/14 номерлы боерыгына 1 нче кушымта (Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының под-722/19 елның «_26_»04.2019 номерлы боерыгы редакциясендә)

Ятим балаларның һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларның моңа кадәр биләп торган торак урыннарында яшәү мөмкинлегенең булмау фактын билгеләү буенча ведомствоара комиссия турында нигезләмә

1. Әлеге нигезләмә түбәндәгеләргә нигезләнеп эшләнде:

«Ятим балаларга һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга социаль ярдәм буенча өстәмә гарантияләр турында» 1996 елның 21 декабрендәге 159-ФЗ номерлы федераль закон;

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Торак урыннары белән тәэмин ителергә тиешле ятим балаларның һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларның, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар исәбендәге затларның, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар категориясенә караган затларның, ятим һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган һәм 23 яшенә җиткән балалар исәбендәге затларның исемлеген формалаштыру, ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар исәбендәге затларны Россия Федерациясе субъектында элеккеге яшәгән урыны буенча исемлектән төшерү һәм аларны Россия Федерациясе субъектында яңа яшәү урыны буенча исемлеккә кертү турында» 2019 елның 4 апрелендәге 397 номерлы карары;

«Ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны торак урыннары белән тәэмин итү турында һәм «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм турында» Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына үзгәреш кертү хакында» 2013 елның 12 гыйнварындагы 8-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы.

2. Ятим балаларның һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларның моңа кадәр биләп торган торак урыннарында яшәү мөмкинлегенең булмау фактын билгеләү буенча ведомствоара комиссия (алга таба – Комиссия) социаль найм шартнамәләре буенча торак урыннарны наемга алучылар яки социаль найм шартнамәсе буенча торак урынны наемга алучының гаилә әгъзалары йә торак урыннар милекчеләре булган ятим балаларга һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар исәбендәге затларга моңа кадәр биләп торган торак урыннарында яшәү мөмкинлегенең булмау фактын билгеләүгә бәйле мәсьәләләрне карау максатында төзелә.

Комиссия срогы чикләнмичә гамәлдә була.

3. Комиссиянең төп бурычлары түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

ятим балаларның моңа кадәр билэп торган торак урыннарында яшәү мөмкинлегенең булуы яки яшәү шартларының булмавы/яшәүнең мөмкин булмавы турында таныклаучы документларга анализ;

файдалану хокукларында яки милекчелек хокукларында моңа кадәр биләгән торак урыннарында ятим балаларның яшәү мөмкинлеге булу/мөмкинлеге булмау фактын билгеләү.

5. Комиссия Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан 12 кешелек составта төзелә. Комиссия составына Комиссия рәисе, рәис урынбасары, җаваплы сәркатип һәм Комиссия әгъзалары керә. Комиссия үз эшчәнлеген түләүсез нигездә гамәлгә ашыра.

Комиссия составы Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары (килешү буенча), шулай ук оешмалар (килешү буенча) вәкилләреннән формалаштырыла, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы боерыгы белән рәсмиләштерелә.

6. Комиссиянең рәисе булып Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министры урынбасары тора, ул:

Комиссия утырышларын билгели;

Комиссия утырышларына рәислек итә;

Комиссия әгъзаларына йөкләмәләр бирә.

Комиссия рәисе вакытлыча булмый торганда аның вазыйфаларын Комиссия рәисе урынбасары башкара.

7. Комиссия утырышлары зарурлык булуга карап уздырыла.

8. Комиссия утырышы, әгәр анда Комиссия әгъзаларының гомуми исәбеннән яртысыннан артыграгы катнашса, тулы хокуклы була.

9. Комиссия утырышларында җаваплы сәркатип тарафыннан беркетмә алып барыла, ул Комиссия рәисе тарафыннан имзалана, ә ул булмаган очракта – Комиссия рәисе урынбасары һәм Комиссиянең җаваплы сәркатибе тарафыннан.

10. Комиссия утырышларын әзерләү эшен оештыру Комиссиянең җаваплы сәркатибе тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Җаваплы сәркатип вакытлыча булмый торган очракларда аның бурычлары Комиссия рәисе карары белән Комиссия әгъзаларының берәрсенә йөкләнә.

11. Социаль найм шартнамәләре буенча торак урыннарны наемга алучылар яки социаль найм шартнамәсе буенча торак урынны наемга алучының гаилә әгъзалары йә торак урыннар милекчеләре булган ятим балаларның моңа кадәр биләп торган торак урыннарында яшәве Комиссия тарафыннан мөмкин түгел дип таныла, әгәр бу хәл «Ятим балаларга һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга социаль ярдәм буенча өстәмә гарантияләр турында» 1996 елның 21 декабрендәге 159-ФЗ номерлы федераль законның 8 статьясының 4 пунктында һәм «Ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны торак урыннары белән тәэмин итү турында һәм «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм турында» Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына үзгәреш кертү хакында» 2013 елның 12 гыйнварындагы 8-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының $2^1$ статьясының 1 өлешендә каралган шартларның берәрсе булуга бәйле рәвештә күрсәтелгән затларның мәнфәгатьләренә каршы килсә:

мондый торак урыннарында теләсә нинди законлы нигездә түбәндәге затлар яшәгәндә:

әлеге ятим балаларга һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар исәбендәге затларга карата ата-ана хокукыннан мәхрүм ителгән затлар (Россия Федерациясе Торак кодексының 72 статьясының 3 өлеше нигезендә торак урынны мәҗбүри алмаштырудан баш тарту турында законлы көченә кергән суд карары булган очракта);

Россия Федерациясе Торак кодексының 51 статьясының 1 өлешендәге 4 пунктында күрсәтелгән исемлеккә туры китереп, мондый авыру вакытында бер торак урында аның белән бергә яшәве мөмкин булмаган хроник авыруларның катлаулы формасы белән интегүче затлар;

хроник эчкечелек, наркомания һәм психик авырулар белән чирләүче һәм тиешле медицина оешмаларында исәптә торучы затлар;

әлеге ятим балаларның гаилә әгъзалары булмаган, торак урыннан файдалануга мөстәкыйль хокукка ия булган затлар;

әлеге ятим балаларны элек уллыкка алган затлар, әгәр уллыкка алу гамәлдән чыгарылган булса;

законнарда билгеләнгән тәртиптә эшкә сәләтсез яки эшкә сәләте чикләнгән дип танылган затлар;

гомергә һәм сәламәтлеккә, җенси кагылгысызлыкка һәм шәхеснең җенси ирегенә каршы, гаиләгә һәм балигъ булмаганнарга, халыкның сәламәтлегенә һәм иҗтимагый әхлакка каршы, шулай ук иҗтимагый иминлеккә каршы җинаятьләр өчен суд хөкемендә яки кайчандыр суд хөкемендә булган яки җинаять эзәрлекләвенә дучар ителүче яки дучар ителгән затлар (аклау нигезләре буенча үзләренә карата җинаять эзәрлекләве туктатылган затлардан тыш);

торак законнарында билгеләнгән нигезләрдә һәм тәртиптә торак урыннары яшәү өчен яраксыз дип танылган затлар;

әлеге торак урында яшәүче бер затка туры килә торган торак урынның гомуми мәйданы торак урын мәйданының исәпкә алу нормасыннан кимрәк булган затлар, шул исәптән, әлеге торак урынга ятим балаларны кертү нәтиҗәсендә шундый кимү барлыкка килгәндә.

12. Ятим балаларга моңа кадәр биләп торган торак урыннарында яшәү мөмкинлегенең булмау фактын билгеләү турында карар Комиссия тарафыннан ятим балаларның яки аларның законлы вәкилләренең язмача гаризасы һәм аңа теркәлүче документлар нигезендә кабул ителә.

13. Гариза фамилиясен, исемен, ата исемен (булган очракта), корреспонденция җибәрү адресын, ятим бала өчен яшәү мөмкинлеге булмау фактын билгеләү турында мәсьәлә куела торган торак урынның адресын, әлеге Нигезләмәнең 11 пунктында саналган шартларны күрсәтеп, ирекле формада төзелә һәм «Татарстан Республикасында дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү күпфункцияле үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе (алга таба – «КФҮ» ДБУ) аша Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына җибәрелә. Татарстан

Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының «КФҮ» ДБУ белән үзара хезмәттәшлеге тиешле килешү нигезендә гамәлгә ашырыла.

14. Ятим балаларның моңа кадәр биләп торган торак урыннарында яшәү мөмкинлеге булмау фактын билгеләү турында гаризага әлеге Нигезләмәнең 14 пунктында саналган шартларның берәрсе булуын раслаучы документлар теркәлә.

15. Гариза һәм аңа теркәлүче документлар «КФҮ» ДБУ аша Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына килгәндә, Комиссия тапшырылган документларга анализ нигезендә ятим балаларның моңа кадәр биләп торган торак урыннарында яшәү мөмкинлеге булмау яки әлеге Нигезләмәнең 11 пунктында күрсәтелгән шартларның булмау фактын билгели.

Карар утырышта катнашкан Комиссия әгъзалары тавышларының гади күпчелеге нигезендә ачык тавыш бирү юлы белән кабул ителә. Комиссия әгъзаларының тавышлары тигез булганда, рәислек итүче затның тавышы хәл иткеч була. Карау нәтиҗәләре буенча бәяләмә рәсмиләштерелә, анда кабул ителгән карар һәм аны мотивацияле нигезләү була. Комиссия тарафыннан гаризаны һәм тапшырылган документларны карауның гомуми срогы алар тапшырылган көннән башлап 14 көннән артык була алмый.

Бәяләмә мөрәҗәгать итүчегә гаризада күрсәтелгән адрес буенча әлеге пунктның икенче абзацында күрсәтелгән срок чикләрендә җибәрелә.

16. Ятим балаларның моңа кадәр биләп торган торак урыннарында яшәү мөмкинлеге булмавы турында бәяләмәләр ятим балаларның шәхси эшләренә тегеп куела. Ятим балаларның шәхси эшләре 75 ел саклана.

17. Комиссия бәяләмәсенә законнарда билгеләнгән тәртиптә шикаять белдерелергә мөмкин.